| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2024 п.г.т.Алексеевское № 192

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел, № 167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 18.04.2024 № 03-12/2677 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре бухгалтерларына һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияларның җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү турында» хатын исәпкә алып

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел, № 167 «Алексеевск муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләр бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифалары | Вазифаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Структур бүлекчә булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен (Башкарма комитет бүлеге, җирле үзидарәнең башка органы) |

| | | |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение житәкчесе | 31700 | |
| Муниципаль учреждение житәкчесе урынбасары | 29500 | 29500 |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе житәкчесе (баш бухгалтер) | | |
| Бүлек башлыгы | 25700 | 25700 |
| Җитәкче бухгалтер | 23300 | 23300 |
| Бухгалтер | 22000 | 22000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазифасын кертү шарты булып структурада штат саны 5 берәмлектән ким булмаган 3 бүлек булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерлык бүлекләренең штат саны 5 берәмлектән ким булмаска тиеш.»

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфаларын башкаручы Е.М. Мифтаховага йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **М.Р. Гайсин**